РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
Нижнекамского муниципального района

423570, г.Нижнекамск, пр.Строителей,12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Түбән Кама муниципаль районы
СОВЕТЫ

423570, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

РЕШЕНИЕ

КАРАР

№ 41

2020 елның 29 апреле

## Түбән Кама муниципаль районы Советының 2006 елның 13 октябрендәге 48 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә иҗтимагый фикер алышулар һәм гавами тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Уставы нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама муниципаль районы Советының 2006 елның 13 октябрендәге 48 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә иҗтимагый фикер алышулар һәм гавами тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2.1 пунктта «яки Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башлыгы» сүзләрен «, Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башлыгы яки Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе» сүзләренә алмаштырырга;

3.7 пунктының 5 абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

4.1 пунктта «Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башлыгы» сүзләреннән соң «яки Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе» сүзләрен өстәргә;

7.2 пунктта «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Советы аппаратының» сүзләрен «иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар үткәрү инициаторы булган Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының тиешле структур бүлекчәсенең» сүзләренә алмаштырырга;

11.2 пунктта «ун көн» сүзләрен «җиде эш көне» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны җирле үзидарә, регламент һәм хокук тәртибе мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама муниципаль
районы Башлыгы

А.Р.Метшин